ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.09.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 203**

Зеленодольск муниципаль районында инвалидлар эшләре буенча Координация советын төзү турында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законы, инвалидларны социаль яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларын гамәлгә ашыру һәм төрле ведомстводагы администрацияләр, оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләрнең, инвалидларга социаль ярдәм өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләрнең структур бүлекчәләре эшчәнлеген координацияләү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы инвалидлары эшләре буенча Координация советы турында нигезләмәне әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районының инвалидлар эшләре буенча Координация советы составын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы
_______________ № _______________
карарына
1 нче номерлы кушымта

Зеленодольск муниципаль районы инвалидлар эшләре буенча координация Советы турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районының инвалидлар эшләре буенча Координация советы (алга таба - Совет) - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы дәүләт хакимияте органнары, органнар һәм структур бүлекчәләр вәкилләреннән, милек хокукына бәйсез рәвештә, оешмалар, учреждениеләр һәм җәмәгатьчелек вәкилләреннән формалаша торган даими эшләүче, коллегиаль, консультатив орган.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә РФ Конституциясе, РФ субъекты, муниципаль берәмлек законнары һәм башка норматив-хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. Совет составы һәм аның рәисе Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана. Совет составы эш барышында үзгәрергә һәм билгеләнгән тәртиптә яңадан расланырга мөмкин.

## II. Совет вәкаләтләре

2.1. Совет Зеленодольск муниципаль районының структур бүлекчәләренең, учреждениеләрнең, оешмаларның, предприятиеләрнең, инвалидлар проблемалары белән шөгыльләнүче иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә.

2.2. Совет инвалидларга карата социаль сәясәтнең төп юнәлешләре буенча Зеленодольск муниципаль районы территориясендә әлеге гражданнарны реабилитацияләү һәм җәмгыятькә интеграцияләү процессын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерли, кызыксынучы ведомстволарның тәкъдимнәрен анализлый.

2.3. Совет тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыручы оешмаларга, учреждениеләргә, халыкның аз мобильле төркемнәре белән эшләүне камилләштерүгә ярдәм итә.

2.4. Совет инвалидлыкны профилактикалау һәм инвалидларны реабилитацияләү өлкәсендә социаль сәясәт мәсьәләләре буенча карарлар һәм күрсәтмәләр проектларына тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә мөмкин.

2.5. Совет инвалидлар проблемалары буенча максатчан программалар эшләүдә катнаша, эшләр барышын анализлый һәм программаларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшли.

2.6. Совет Башкарма комитет җитәкчесенә инвалидларның хәле һәм районда инвалидлык проблемалары турында хәбәр итә.

## III. Совет хокуклары

Үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Координация советы түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1. Билгеләнгән тәртиптә, компетенция кысаларында башкарма хакимият органнарыннан, оешмалардан, учреждениеләрдән һәм иҗтимагый берләшмәләрдән кирәкле мәгълүмат соратып алырга һәм алырга.

3.2. Координация советы утырышларына материаллар әзерләү өчен эш төркемнәре булдырырга.

3.3. Башкарма хакимият органнары, оешмалар, учреждениеләр, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен чакырып киңәшмәләр, консультацияләр һәм башка чаралар оештырырга һәм уздырырга.

3.4. Үзләренең утырышларында кызыксынган ведомстволарның мәгълүматларын, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңларга.

## IV. Совет эшен оештыру

4.1. Совет утырышлары кирәк булган саен үткәрелә, ләкин ярты елга кимендә 1 тапкыр уздырыла. Чираттагы утырышның датасы, үткәрелү урыны һәм көн тәртибе турында координация советы әгъзалары аны уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш. Координация советы әгъзасы нинди дә булса сәбәпләр аркасында утырышта катнаша алмаган очракта, ул алдан ук координация советы сәркатибенә хәбәр итәргә тиеш.

4.2. Совет утырышы, әгәр анда координация советы әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы. Координация советы карарлары утырышта катнашучы Совет әгъзалары санынннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

4.3. Совет утырышында җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары, оешмалар, учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.4. Совет карарлары киңәш характерында һәм беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

4.5. Координация советы расланган план нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## V. Башка оешмалар, учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр белән үзара бәйләнеш

5.1. Совет чит оешмалардан, учреждениеләрдән, иҗтимагый берләшмәләрдән белгечләрне түләүсез нигездә эшкә җәлеп итәргә хокуклы.

## VI. Совет эшчәнлеген туктату

6.1. Совет эшчәнлеге Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән туктатыла.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы
________________ № ______________
карарына
2 нче номерлы кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
инвалидлар эшләре буенча Координация советы
**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Тыгин<br>Александр Васильевич | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Координация советы рәисе |
| 2. | Сәхибуллин<br>Айрат Хадисович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Координация советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Нуриева Гюзелия<br>Наил кызы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы, Координация советы сәркатибе (килешү буенча) |

**Комиссия әгъзалары**

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Лежнина<br>Алеся Анатольевна | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының социаль өлкәдә җирле үзидарә органнарын координацияләү буенча җәмәгать ярдәмчесе |
| 5. | Коршунов<br>Александр Николаевич | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы |
| 6. | Хәлилова<br>Лилия Шаукатовна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр), комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 7. | Афанасьева<br>Раиса Вәлиева | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы мәгариф идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Нигъмәтуллин | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма |

| | | |
|---|---|---|
| | Азат Фәрит улы | комитетының Яшьләр эшләре, спорт идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| 9. | Дегтева Ольга Павловна | «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 10. | Шәрифҗанова Аида Ринатовна | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 11. | Динмөхәммәтова Альбина Рапхатовна | Зеленодольск шәһәре Советының социаль мәсьәләләр, экология һәм табигатьтән файдалану буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| 12. | Гатин Фоат Фатыйх улы | Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр һәм сәламәтлек саклау буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| 13. | Сабурский Алексей Вячеславоич | Россия Федерациясе Пенсия Фондының Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре, Зеленодольск һәм Югары Ослан районнары буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 14. | Һидиятов Илгиз Ринат улы | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| 15. | Витовская Татьяна Владимировна | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Зеленый Дол» мәгълүмат үзәге» директоры (килешү буенча) |
| 16. | Завилейская Илсөя Мансуровна | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Яшел Үзән» газетасы редакциясе» баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 17. | Гыйззәтуллин Тәлгать Рифкат улы | Район һәм шәһәрнең сугыш һәм хезмәт ветераннарының (пенсионерларының) иҗтимагый оешмасы, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органнары советы рәисе (килешү буенча) |